Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Әлмәт авылы башкарма комитеты

КАРАРЫ

20 октября 2022 ел № 18

Әлмәт муниципаль районы Әлмәт авылы башкарма комитетының 2017 елның 29 декабрьдәге 12 номерлы «Әлмәт муниципаль районының Әлмәт авыл җирлеге кешеләр күпләп була торган торак секторда һәм объектларда янгын-профилактика эшен оештыру турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Янгын куркынычсызлыгы турында»1994 елның 18 ноябрендәге 719 номерлы карары нигезендә

Әлмәт авылы башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Әлмәт авылы башкарма комитетының 2018 елның 29 декабрьдәге 12 номерлы «Әлмәт муниципаль районының Әлмәт авыл җирлеге кешеләр күпләп була торган торак секторда һәм объектларда янгын-профилактика эшен оештыру турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

I бүлекнең 3 пункты тугызынчы абзацында «Янгынга каршы пропаганда - җәмгыятькә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү проблемалары һәм юллары турында максатчан мәгълүмат бирү,» сүзләрен «Янгынга каршы пропаганда - җәмгыятькә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү юллары турында хәбәр итү,» сүзләренә, «җайланма» сүзен «уздыру» сүзенә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Яшьләр бистәсе, Комсомол ур., Дербедень авылы, Совет урамында урнашкан махсус стендларда игълан итәргә, шулай ук "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында "(PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылганнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырым.

Әлмәт авылы башкарма
комитеты җитәкчесе В.И.Газизова